| | |
|---|---|
| ГЛАВА КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от 28.10.2020 г. Кошман ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2020 елның 16 ноябренә 14 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 31 йорт адресы буенча урнашкан Кошман төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2020 елның 16 ноябренә 16 сәг 00 минутка Кошман авылы, Мәктәп ур, 39 йорт адресы буенча урнашкан Кошман балалар бакчасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2020 елның 17 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2020 елның 17 ноябренә 16 сәг 00 минутка "Дубрава" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Кошман филиалының сөтчелек фермасы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2020 елның 18 ноябренә 10 сәг 00 минутка Кошман авылы, Сәгыйди ур, 59 йорт адресы буенча урнашкан ШЭ Гафиятуллин С.Л.ның "Алинә"

кибете бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә.

6. 2020 елның 19 ноябренә 15 сәг 00 минутка Кошман авылы, Үзәк ур, 16 йорт адресы буенча урнашкан Кошман авылы мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын билгеләргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кошман авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

-буаны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пунктның чүплекләре территорияләрен чистарту;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

-суүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- су башняларын лицензияләү буенча түләү (санитар-эпидемиологик бәяләмәне документлар белән рәсмиләштерү, су белән тәэмин итү чыганагының куллануга яраклы булуын раслауга, суны анализлауга һәм башка документларны документаль рәсмиләштерү);

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

-юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту (җәйге чорда территорияне чабу, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).»

« РИЗА» «КАРШЫ»

7.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Кушманского сельского поселения Кошман авыл җирлеге Советы

Башлык Л.Р. Сафина